КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 октябрь г.Казань № 1311

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында» 2016 ел, 11 июль, 473 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламентын раслау турында» 2016 ел, 11 июль, 473 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Кеше күп катнаша торган чараларны медицина ягыннан тәэмин итүне оештырганда хезмәттәшлек итү регламентында:

2 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин